ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

от 08.02.2021ел №07-08

«Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендә кабул ителгән 22-02 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8.20 пунктына «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

1.2. түбәндәге эчтәлектәге 11.3 пунктын өстәргә:

-«11.3. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»;

1.3. 17.3 пунктының 4 пунктчасында «һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң өстәргә;

1.4. 25.13 пунктының 2 пунктчасында «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яки)» сүзләрен «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләренә кадәр өстәргә;

1.5. 27.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «27.2. Муниципаль хезмәт стажын раслый торган төп документлар булып, билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр тора»;

1.6. 27.4 пунктында «хезмәт кенәгәсендә» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

1.7. 31.2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе Э.Н. Фәттахов